ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 77-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов, Ф.Ф. Баһаветдинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 77-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 310-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев,
Н.Н. Хаҗипов,
Ф.Ф. Баһаветдинов
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнар милкенә бирү (тапшыру), Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{10}$ статьясындагы 1 һәм 3 пунктларында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, түләүсез башкарыла.»;

2) $32^1$ статьяның 15 пунктындагы 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{19}$ статьясындагы 3 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеге гражданнар милкенә Россия Федерациясе Җир кодексының $39^5$ статьясындагы 6 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча түләүсез бирелгән (тапшырылган) булса;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^{1}$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Россия Федерациясе Җир кодексының (алга таба – РФ Җир кодексы) $39^{5}$ статьясында Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген түбәндәгеләр милкенә түләүсез бирү мөмкинлеге беркетелгән:

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән очракта һәм тәртиптә өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга (6 пунктча);

әлеге статьяның 6 пунктчасында күрсәтелмәгән, федераль законнарда каралган очракларда башка аерым категориядәге гражданнарга һәм (яисә) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларга, Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда аерым категориядәге гражданнарга (7 пунктча).

РФ Җир кодексының $39^{19}$ статьясындагы 1 пунктында аерым категориядәге гражданнарга җир кишәрлекләрен күрсәтелгән нигезләр буенча милеккә түләүсез бирү бер тапкыр башкарыла дип билгеләнгән. Әгәр гражданның РФ Җир кодексының $39^{5}$ статьясындагы 6 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән берничә нигез буенча җир кишәрлеген милеккә түләүсез алу хокукы булса, бу граждан җир кишәрлеген милеккә түләүсез күрсәтелгән нигезләрнең берсе буенча гына алырга хокуклы.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 20 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон белән РФ Җир кодексының $39^{19}$ статьясына 3 пункт өстәлгән, анда РФ Җир кодексының $39^{5}$ статьясындагы 6 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча җир кишәрлекләрен гражданнарга милеккә бер тапкыр түләүсез бирү турындагы шартлар кулланылмый торган очраклар билгеләнә.

Күрсәтелгән нигезләр буенча элек бирелгән җир кишәрлегеннән аның максатчан билгеләнешенә һәм рөхсәт ителгән кулланылышына ярашлы рәвештә файдалануның сугыш хәрәкәтләре һәм (яисә) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында мөмкин булмавы мондый искәрмәләргә керә.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Җир кодексының (алга таба – ТР Җир кодексы) дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә бирүне җайга сала торган 32 статьясына җир кишәрлекләрен гражданнар милкенә түләүсез бирүнең Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{10}$ статьясындагы 1 һәм 3 пунктларында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып башкарылуы турындагы нигезләмә өстәлә.

Закон проектында шулай ук ТР Җир кодексының өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарны җир кишәрлеге милеккә түләүсез бирелү хокукына ия гражданнар исемлекләреннән төшереп калдыру һәм аларга җир кишәрлеген бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр билгеләнгән $32^{1}$ статьясындагы 15 пунктның 1 пунктчасына үзгәреш кертү һәм тиешле карарның, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{19}$ статьясындагы 3 пунктында каралган очраклардан тыш, җир кишәрлеге гражданнар милкенә Россия Федерациясе Җир

кодексының $39^5$ статьясындагы 6 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча түләүсез бирелгән очракта кабул ителүен билгеләү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^{1}$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^{1}$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.